
Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы

# Мәктәп пульсы



## Безнең йөрәкләрдә син Тукай !

№8
Апрель, 2023 г.



**В этом выпуске:**



| | |
|---|---|
| Из школьной жизни... | 2 |
| День космонавтики | 3 |
| Из школьной жизни... | 4 |
| Мәктәптә мәртәбәле кунак | 5 |
| Мәктәптә мәртәбәле кунак | 6 |



Апрель аенда без бөек шагыйребез Габдулла Тукай туган көнне билгеләп үтәбез. Моннан 128 ел элек, 1886 нчы елның 26 нчы апрелендә дөньяга килеп, 110ел элек, ягъни 1913 нче елның 3 нче апрель иртәсендә дөньядан китеп тә барган Тукай бүген дә безнең арабызда кебек. Аның иҗаты, аның геройлары безнең күңелләрдә, безнең җаныбызда.

Г.Тукай бик аз яшәгән. Аның балачагы бик авыр булган, ул кечкенәдән ятим калып, төрле гаиләләрдә тәрбияләнеп үскән. Г. Тукай дөньяда бары тик 27 ел гына яшәгән, бары 8 ел гына иҗат иткән. Шулай булса да ул гаять зур, бәя биреп бетермәслек рухи байлык калдырган. Аның тормышы һәм иҗаты- халкыбыз тарихында иң якты, иң изге сәхифәләрнең берсе.


Бөек шагыйребез җәүһәрләре республикабыз исемен дөньякүләм ишеттерүдә, татар милләтен танытуда зур әһәмияткә ия. Шунысы шатлыклы, Габдулла Тукай иҗаты районыбыздагы һәр мәктәпкә бүләк игелде.Тукайның мәңге яшәр иҗаты безне алга таба да изге эшләргә һәм игелекле гамәлләр кылуга рухландырыр, юл күрсәтүче маяк булып балкыр!

# Из школьной жизни...



С 1 апреля стартовал санитарно-экологический двухмесячник по очистке территорий Арского муниципального района.

3 апреля трудовой коллектив принял участие в субботнике. Работники привели в порядок территорию школы, очистили газоны от прошлогодней листвы. Субботники будут продолжены пока территория полностью не будет очищена. #всероссийскийсубботник #ЭКОВЕСНА2023




Ученики 8 класса А встретились с нашим земляком-патриотом Алмазом Исламовым, который принимал участие в специальной военной операции на Украине. Ученики внимательно слушали об украинских детях, о том, как они живут. На этой встрече состоялась содержательная беседа, в которой можно было подумать о том, в каких условиях они учатся, живут.





Новая учебная четверть началась с традиционной торжественной линейки, выноса государственного флага и исполнения гимна Российской Федерации и Республики Татарстан.

Право внести флаг было предоставлено Юнармейцам, Абдуллиной Камиле, Гарифзяновой Камиле-ученицы 10 класса.

А так же награждали учеников школы, отличившихся в творчестве, в спорте.



Наши активисты школьного ученического самоуправления принимают участие в масштабном молодежном форуме «Алга! Поехали!»

За три дня их познакомят с опытом работы профильных учреждений и с публичными деятелями республики.

# *День космонавтики*

*Это всенародный праздник. Пройдут годы, десятилетия, века, но люди будут помнить, что именно с этого дня – 12 апреля 1961 года — человек начал освоение космоса.*

*Для нас кажется привычным, что стартуют с Земли космические корабли, месяцами на космических станциях живут и трудятся космонавты, уходят к другим планетам автоматические станции.*

*Вы можете сказать «Что тут особенного», но ведь совсем недавно о космических полетах говорили как о фантастике.*

*Ребята не остались в стороне от чествования космонавтов и под руководством своих классных руководителей организовали выставку, посвящённую Дню космонавтики.*












# Из школьной жизни...



У нас в школе проходила акция « Письмо солдатам СВО» . 2Б класс принял активное участие. Один из войнов получил письмо от нашей Сухих Арины! Приехав домой в отпуск он нашел нашу школу, Арину и лично поблагодарил ее за письмо, за слова поддержки. Встреча была очень трогательная…



4 апреля в малом зале администрации Арского муниципального района состоялось первое заседание Клуба молодых избирателей. Из нашей школы приняли участие ученицы 8 класса Абдрахманова К. и Гатауллина А.

Встреча была посвящена основным общественно-политическим процессам в стране и республике, важности участия молодых людей в федеральных и республиканских выборных кампаниях.







Во время работы стажировочной площадки для директоров школ на базе АСОШ2 сегодня мы принимали гостей из Высокогорского района Республики Татарстан и Ямало-Ненецкий автономный округ. В рамках стажировки гостей познакомили с направлениями работы по воспитанию гражданственности и патриотизма на занятиях объединений по интересам и в детских движениях.



# Мәктәптә мәртәбәле кунак





Озак еллар педагогия көллиятендә укыткан якташыбыз Фәрит Минхәировны районадашларыбыз туризм өлкәсен үстерүгә зур өлеш керткән шәхес буларак белә. Шулай ук ул сәламәтлекләре чикләнгән балалар белән бочче секциясен ачып җибәрде һәм уңышларга иреште.

"Куркынычсызлык мәктәбе" ярышларын үстерү буенча озак еллар нәтиҗәле эшләве өчен якташыбыз Фәрит Минхәиров "Куркынычсызлык мәктәбе" Бөтенроссия балалар-яшүсмерләр иҗтимагый хәрәкәтенең "Куркынычсызлык культурасын пропагандалау өчен" медале белән бүләкләнде.

Татарстанның атказанган физик культура хезмәткәре, Россиянең физик культура һәм спорт отличнигы, Халык мәгарифе отличнигы, балалар һәм яшүсмерләр туризмы профессоры! Россиядә "Турист дистанциядә" дигән методик китаб белән җинүче булды. Шулай ук Россиядә иң беренче булып туризм буенча зал ярышлары уйлап табучы буларак танылды. Татарстанда иң яхшы туризм тренеры. Хезмәтләрем югары бәяләнде, профессор исеме бирделәр.

Иң яраткан һөнәре туризм. Рюкзагыңны асып, сәяхәткә чыгып киткәч, төймән төшсә, анда әби, әни юк, үзең тагарга өйрәнәсең. Ашарга пешерергә, табак-савыт юарга, агач-богач җыярга, учак көйрәтергә, иптәшлекне аңларга, табигатьне яратырга, авырлыкларны җиңәргә – күп нәрсәгә өйрәнә бала. 4–9 сыйныф укучылары белән эшлим".





Әкренләп сүз боччега күчте. “2013 елда оештык без, – дип сөйләде Фәрит Фәтхиевич. – Крутушкага бочче ярышын карарга гына барган идем, югыйсә. Сәламәтлегем буенча үзем дә 2нче төркемдәге инвалид мин. 2010 елда инсульт булды, 2011 елда йөрәгемә җитди операция ясаттым. Бүген миңа 66 яшь. 2013 елда районда инвалид балалар белән бочче секциясе оештырырга уйладым. Һәм башлап җибәрдем, җиңел булмады. Район социаль яклау бүлегеннән исемлекне бирделәр. Шул исемлекне тотып, хәрәкәтләре чикләнгән балаларга чыгып киттем. Төймәгә басам, ишекне ачалар, ә анда мин – таныш түгел кеше басып тора. Менә шулай.., команда җыям, мин әйтәм. Түләүлеме, дип сорыйлар. Юк, бушка дим, шалт итеп ишекне ябып куялар. Аферист, дип уйлаганнардыр инде. Ничек инде, мөмкинлеге чикләнгән бала белән бушка шөгыльләнсеннәр, ди?! Башта бушка, аннан акча сорар! Белеп алгач, риза булдылар. Бочченың туплары кыйммәт тора. Киттем спонсорлар эзләп. “Арча КСМы” ширкәте җитәкчесе Рафаэль Муллагалиевка кердем. Изге эш белән йөрисең икән дип, Рафаэль Әдһәмович ярдәм итәргә риза булды. Ул вакытта бер комплект 10 туп 17 мең сум тора иде, хәзер 30 мең сум. Ике комплект туп алып бирделәр. Рәхмәт. Бүген секциядә 8 бала шөгыльләнә. 2шәр сәгать атнага өч тапкыр. Яраталар. Бердән, алар дөньяга чыга, иптәшләре белән аралашалар, икенчедән, бочче кызыклы һәм файдалы уен, баланың начар хәрәкәтләнгән кулы һәм башы да яхшырак эшли башлый һ.б.

Тора-бара начар хәрәкәт-ләнгән кулның кашык тота алуы һәм баланың шул кул белән ашый башлавы – менә бу чын җиңү! Аларның үзләренең интернетта “Арча бочче” төркеме бар. Әле менә күптән түгел Рамил Шәрәфетдинов Россия чемпионы булды.

Без “йөрәк” турында да сүз кузгаттык. “Балаларның иртәгә дә киләбезме, дип сораганына, юк, дип әйтә алмыйча, атнага ике генә көн шөгыльләнәсе урынга 5-7 көн рәттән бирелеп эшләүләр, күрәсең, йөрәккә көч китергән...”

Фәрит Фәтхиевич очрашуга ашыкты. Ә без Көтек авылыннан Фәния ханым белән элемтәгә кердек. “Боччега кызыбыз Зәринә йөри, – дип сөйләде ул. – 4-5 еллап бар инде. Үзем машинада. Атнага өч тапкыр килергә тырышабыз. Балага иң мөһиме иптәшләре белән аралашу. Тренер Фәрит Фәтхиевичны бик яратабыз, хөрмәт итәбез. Ул үзе дә балаларны ярата, алар белән сөйләшә, аралаша, һәркайсына шәхси якын килә белә. Нәтиҗәләрне күреп сөенәбез. Бик зур рәхмәт”.






***Редактор*** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.

***Дизайнер - верстальщик*** Алсу Минһаҗева

***Фотокорреспондент*** Ранис Исмагилов

***Корректор*** Ислам Мингазов

***Редколлегия*** Ислам Сафин

Гүзәлия Фәттахова

***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15

***Сайт школы*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2